**Муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына җибәрү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында килешү**

**Аксубай ш.т.п.** **«01» июнь 2025 ел**

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Уставы нигезендә эш итүче, алга таба «Район башлыгы» дип аталучы Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башлыгы вазифасын вакытлыча башкаручы Заһидуллин Илшат Минсабирович, бер яктан, һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге башлыгы Зюзина Татьяна Викторовна Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Уставы нигезендә эш итә, икенче яктан, алга таба «Җирлек башлыгы», «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (алга таба - 14-ТРЗ номерлы Закон), «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районнарга керүче җирлекләрдән мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын , (алга таба - 92-ТРЗ номерлы Закон) гамәлгә ашыру максатларында бергә «Яклар» дип аталып түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

***1.Килешү Предметы***

Килешүнең предметы булып 92-ТРЗ номерлы Законны гамәлгә ашыру максатларында муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында 14 - ТРЗ номерлы Законның 5 статьясында билгеләнгән белешмәләрне (алга таба шулай ук - документлар) җыю һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына (алга таба шулай ук-регистр) җибәрү мәсьәләләре буенча район башлыгы белән җирлек башлыгының үзара хезмәттәшлеген оештыру тора.

**2. Якларның хокуклары һәм бурычлары**

Район башлыгы җирлек башлыгыннан документлар кабул итүне һәм аларны регистрга 14-ТРЗ номерлы законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда җибәрүне тәэмин итә.

Җирлек башлыгы тәэмин итә:

документларны 14-ТРЗ номерлы законда билгеләнгән нормалар һәм таләпләр нигезендә рәсмиләштерү;

регистрга кертү өчен җибәрелә торган документларның тулылыгы һәм 14-ТРЗ номерлы законда билгеләнгән белешмәләрнең дөреслеге;

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турындагы белешмәләрне җыю һәм җибәрү буенча үзара хезмәттәшлек турындагы Район башлыгының 2015 елның 30 декабрендәге 52 номерлы карары белән расланган регламент нигезендә билгеләнгән җирле үзидарә органына (вазыйфаи затына) документларны тапшыру

**3.Килешүнең гамәлдә булу вакыты**

Әлеге килешү билгесез вакытка төзелде.

**4.Килешүне туктату нигезләре һәм тәртибе**

Әлеге Килешү вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

якларның килешүе буенча;

якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта.

**5. Якларның Җаваплылыгы**

Якларның килешү шартларын үтәмәве яисә тиешенчә үтәмәве килешүне берьяклы өзү өчен нигез булып тора

**6. Йомгаклау нигезләмәләре**

6.1. Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр якларның үзара ризалыгы белән кертелә һәм язма рәвештә өстәмә килешү белән рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр әлеге килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

6.2. Килешү бертигез юридик көчкә ия ике нөсхәдә, һәр як өчен берәр нөсхәдә төзелде.

**7. Якларның Имзалары**

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы<br>Аксубай муниципаль районы<br>Башлыгы вазыйфаларын<br>вакытлыча башкаручы<br>__________ Н.М.Заһидуллин | Татарстан Республикасы<br>Аксубай муниципаль районы<br><br>Мюд авыл җирлеге башлыгы<br>__________ Т.В. Зюзина |